# İdegey Destanında Bazı Motifler*

Yard. Doç. Dr. Çulpan ZARİPOVA ÇETİN

Muğla Üniversitesi Fen-Edebiyat Fakültesi

Çağdaş Türk Lehçeleri ve Edebiyatları Bölümü Öğretim Üyesi

## "İdegäy" Dastanında Qayber Motivlar

Ruxi dönya mädäniätendä dastannar ayırım urın alıp toralar häm bezgä tege yäki bu xalıqnıñ iñ borıñğı yäşäw häm fikerläw räweşen citkerüdä möhim çığanaqlarnıñ berse. Xalıq xätere üzeneñ iñ borıñğı yolaların, ğöref-ğädätlären, ışanuların saqlap qalıp, alarnı xäzerge waqıtqa qädär kitergän. Häm iñ ähämiätlese — epik dastan ber millätneñ genä tügel, ä bälki ber xalıq bulıp oyışqan küp kenä millätlärneñ ütkänen bilgele ber däräcädä çağıldıra. «İdegäy» dastanında da, tatar xalqınıñ omtılışları, xolqı, ğöref-ğädätläre sürätlänüe belän bergä, başqa törkilärneñ ışanuları, däwlät totu tärtipläre, ğailä-könküreş yolaları kiñ urın alğan. Anda taswirlanğan waqıyğalar ber-berläre belän tığız tarixi häm mädäni bäyläneştä yäşägän küp kenä törki qäbilälärne üz eçenä sıydırğan ber däwlättä — Altın Urdada (1241-1502) buluın onıtmasqa kiräk. Läkin dastannı analízlaw barışında tatarlar belän bergä, qıpçaq törkemenä kergän başqort, nuğay, qırğız häm qazaqlarnıñ ğöref-ğädätlärenä häm ışanularına da möräcäğät itüne kiräk taptıq: çönki yarımküçmä, yarımutraq xäyät kiçergän älege xalıqlarnıñ mädäniäte xaqlı räweştä Altın Urda mädäniäteneñ ayırılğısız ber öleşe bulıp isäplänä[1].
Altın Urda xökemdarları Çıñğız näselennän buluları, alarnıñ assimilasialäşüenä qaramastan, monğollarğa xas üzençälekle ğöref-ğädätlärgä tuğrılıqlı qalğannar. Şuña kürä, bezneñ älege tikşerenüebezdä, törkilärneñ ğöref-ğädätläre belän bergä monğollarnıñ borıñğı dinen öyrängän fransuz ğälime Jan Pol' Runıñ xezmäte dä bilgele ber yünäleş bulıp tora. Ğömümän, bu ike xalıqnıñ bötendönya sosial', iqtisadi häm mädäni tormışında zur rol' uynawları mäğlüm. Çönki borıñğı däwerdä alar belän aralaşmıyça bik az xalıq qalğandır[2]. Läkin «İdegäy» dastanın tikşerü öçen monğollarnıñ häm böten törki xalıqlarnıñ könküreşen, ğöref-ğädätlären genä tügel, ä bälki, alar bu cirlärgä kilep urnaşqançı, biredä yäşägän skiflarnıñ häm hunnarnıñ, alay ğına da tügel — böten aldıñğı sivilizasialärneñ köndälek tormışın, ışanuların, yolaların da belü zarur.

---

* Bu makale  Kazan'da Tataristan Cumhuriyeti Arşivler Müdürlüğü yayını olan "Ğasırlar awazı"("Eho Vekov") adlı dergide Tatar Türkçesinde yayınlanmıştır ( 2006, N- 1). Burada Tatar Türkçesinde olan metin Tatarlar tarafından kabul edilen Latin alfabesi ile verilmekte.

[1] Suleymanowa-Waleyewä G. Tipologia vzaímodeystwiä xudojestwennoy kulturı tatar v sisteme «Wostoq — Zapad» // Tatarica. Zwezdnıy ças tatarsqoy istorii. Qazan, 1997, s. 113.
[2] Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların Eski Dini / Çeviren A. Kazancıgil. – İstanbul.  2 baskı. 1998, s. 14.

«İdegäy» — mifologia belän bäyläneşle bik siräk häm çınbarlıqqa iñ yaqın dastannardan sanalsa da, anda mäcüsilek çorı belän bäyle urınnar da yış oçrıy. Çönki älege çor tatarlarnıñ könküreşenä, tormış fälsäfäsenä dä zur yoğıntı yasağan. Íslam dine qabul itelgännän soñ mäcüsilek belän bäyle xäräkätlär (küräzäçelek, qarğış, tabiğät köçlärennän yärdäm soraw h. b.) keşelärneñ küñellärendä saqlanıp kilgän. Şuña kürä «İdegäy» dastanı íslam dineneñ däwlät tärtibenä häm xalıq añına nıqlap urnaşqan ber çorda barlıqqa kilgän buluına qaramastan, anıñ qaharmannarı yış qına «Allahım» diäse urında «Tañrem» dilär. Bälki monıñ säbäbe, tañreçelekneñ keşene tabiğätkä yaqınaytuı häm tormışındağı törle ışanularğa, küräzälek, sixer kebek köçle täesirlärgä şaqtıy zur urın birgän ışanu sisteması buluındadır? A. İnan yazğança, «Çiñğız xan tiräsendä tuplanğan törki xalıqlar häm monğollar, başqa dinnärneñ täesirendä qalıp, mäcüsilektän şaqtıy yıraqlaşqannar. Läkin, moña qaramastan, monğol yawı Urta Aziä häm İdel buyı möselmannarında inde yuğalıp barğan mäcüsilek qıypılçıqlarınıñ yañadan canlanıp kitüenä säbäpçe buldı. Şuña kürä monğol yawınnan soñ yazılğan çığanaqlarda mäcüsilek belän bäyle mäğlümatlar kübräk»[3]. Tarix bezgä monğollarnıñ barlıq dinnärgä dä xörmät belän qarawları turında söyli. Çiñğızdan kilgän ğädät buyınça Altın Urda däwlätendä dä dinnär irege saqlanğan bula.
Ğöref-ğädätlär — barlıq xalıqlarğa, millätlärgä xas urtaq küreneş. Alarğa qarap här millätneñ taríxın, ruxi xaläten, mentalitetın tanırğa öyränäbez.
Ber däwlät eçendä, xätta kürşe däwlätlärdä yäşägän xalıqlar, ber-bersenä, älbättä, täesir itmi qalmağannar. Ä inde ışanularğa kilgändä, alarnı — här xalıqnıñ taríxı, mädäniäte, asılı, milli barlığı dip sanarğa xaqıbız bar.
Şul räweşle, «İdegäy» dastanında, xäzerge waqıtta bik ük añlaşılıp betmägän ğöref-ğädätlär häm tormış-könküreş belän bäyle detällär dä oçramıy tügel. Alarnıñ qıpçaq törkemenä kertelgän häm XX ğasırğa qädär küçmä tormış belän yäşäwlären däwam itkän başqa törki xalıqlarnıñ (qazaq, qırğız) köndälek tormışına xas bulıp, alarda bügengäçä saqlanıp kilüe bezgä qızıqlı ğına tikşerenü yasarğa mömkinlek birä.
Bügenge törki dönyanıñ nigez taşı bulıp sanalğan urtaq ğöref-ğädätlär, ışanular arasındağı bäyläneşkä kilgändä isä, ul tağın ber märtäbä törki xalıqlarnıñ tarixi berlegen häm bötenlegen kürsätep toruçı faktorlarnıñ berse bulıp qala.

**Ğailä-könküreş yolalarınıñ çağılışı**.

Xalıq awız ícatında ğailä-könküreş yolaları öç törgä bülenä: öylänü-nikax, bala tuuı häm wafat bulu. Alar törle ğöref-ğädätlär häm ışanular belän tığız ürelgän. Ğailädä ütkärelä torğan yolalar, keşene törle qara köçlärdän saqlap qalu yulların kürsätü belän bergä, keşe qäderen añlarğa da yärdäm itälär. Barlıq törki dastannarda ähämiätle urın alıp torğan älege yolalar, íslam dine qabul itelgänçe, babalarıbız yäşägän mäcüsilek däwereneñ ezlären dä saqlıylar.

**I. Öylänü.**

Ğailä qoru, anı yaman keşelärdän, doşmannardan saqlaw — qaharmanlıq dastannarına xas töp temalarnıñ berse.
«İdegäy» dastanında berençe märtäbä tuy töp qaharmannıñ öylänüe belän bäyle räweştä telgä alına:

[3] İnan A. Tarihte ve Bugün Şamanizm. Ankara, 1995, s. 11-12.

*Ber bite ayday balqığan,*
*Ber bite köndäy salqığan,*
*Bolğardayın bolqığan,*
*Cofardayın añqığan*
*Aytulı aru qız ikän —*
*Tuyınnan tuyın qıldırıp,*
*Söyärenä anı aldı. (35)*[4]*4*

İdegäyneñ İdel-yortqa qarata äytkän süzläre:

*Atam kiäw bulğan yort —*
*İelep täzem qılğan yort;*
*Anam kilen bulğan yort —*
*İelep sälam äytkän yort. (132)*

*I. 1. İelep täzem qılğan yort.*

Tuynıñ iñ ähämiätle öleşe — qıznıñ kilen bulıp kiäw öyenä töşüeder, möğäyen. Bu uñaydan, bik borıñğı çorlardan birle, törki xalıqlarğa xas bulğan «ğailä uçağı» töşençäsen qarap ütü zarur. Öydä yanğan uçaq — ul ğailä simwolı bulğan. Öylänü, nikax belän bäyle yolalar da näq menä uçaq, ut qültınnan tuğan ışanular nigezendä başqarılğannar. Uçaq qültı dastannarğa da ütep kergän häm alarda yaxşı ğına cirlek tapqan. Äwwäl Altay xalqınıñ geroik «Alıp Manas» eposına iğtibarnı yünältik:

*Al Qağan bar ide,*
*Anıñ ir yöze kürmägän,*
*İr qulı timägän*
*İrkä-Qaraqçı isemle qızı bar ide.*
*Uçağımnı anıñ belän bergä yaqtım*[5]*.*

Kiäw öyenä kilgän kilenneñ berençe eşe uçaqqa xörmät kürsätü bulğan. A. İnan yazğança, «yaña kilen bulıp töşkän qızlarnıñ ata çatırınıñ uçağındağı utqa ielep sälam birülären» üze dä küp märtäbä kürgän. «Qazaqlar moña «täcim» dilär, härxäldä ğäräpçädän «tağzıym» süzeneñ bozılıp äytelüe bulsa kiräk», dip östi ğälim[6]. Mäsälän, «Manas» dastanında Aq-Sayqal Xatın, nikaxtan soñ iñ berençe eşe itep, ielep ğailä uçağına sälam birä. Altay xalqında qız yäräşelgän yegeteneñ öyenä kilgäç, şulay uq berençe çiratta, cirgä qädär ielep, uçaqqa xörmät kürsätkän. Aña «uçağıñ berqayçan da sünmäsen!» dip teläk telägännär[7]. Dimäk, kilen bulıp töşkänçe ük qızlar uçaqqa üzläreneñ xörmätlären kürsätergä tieş bulğannar. Mondıy faqtlar barlıq törki xalıqlar öçen dä xas bulğan. Läkin älege yolanıñ xäzergä qädär näq menä altaylılarda saqlanıp kilüe — alarnıñ sivilizasia yoğıntısınnan yıraq qaluları näticäse bularaq qabul itelergä mömkin. Makedoniadä yäşägän töreklärdä dä kilen bulıp töşkän qıznı iñ elek uçaq yanına kiterälär häm ul uçaqqa sälam birergä tieş.

---

[4] İdegäy. Tatar xalıq dastanı. Qazan, 1988, s. 254 (Misallar älege çığanaqtan alındı häm bit sannarı şunnan kürsätelä. — Ç. Z.-Ç.).
[5] Ergun M. Alıp Manas. Ankara, 1998, s. 102.
[6] İnan A. Makeleler ve İncelemeler. Ankara, 1987. Cilt 1, s. 140-141.
[7] Őgel B. Türk Mifolojisi. Ankara, 1993. Cilt 1, s. 105.

«İdegäy» dastanında isä İdegäyneñ kilen bulıp töşkän änise genä tügel, kiäw bulğan atası da, uçaq aldına kilep, ielep täzem qıla. Mäsälän, qazaqlarda häm qırğızlarda kiäw keşe äle bügen dä qız öyenä kergäç, qıznıñ atasına, anasına häm babalarınıñ ruxına öç märtäbä ielep xörmäten kürsätergä tieş. Läkin dastanda «ielep täzem qılğan yort» digän yullardağı «täzem» süze bu küreneşne uçaq qültı belän qararğa mömkinlek birä.

*I. 2. İelep ayaq alu.*

«İdegäy» dastanında kilen bulıp töşkän Yänikäneñ, tezen çügep, ayaq (qäsä) belän bal (eçemlek) alıp eçüe äytelä. Ul — kilenneñ mul, sıylı tormışta yäşäwen teläw belän bäyle. Qazaqlarda xäzer dä kiäw keşe, qıznı alırğa kilgäç, anası aña ber qäsä qımız suzıp, matur teläklär äytä[8]. Bu ğädät qırğızlarda da bar. Ä tatarlarda isä, ul kiäw keşegä tügel, kilengä yünältelgän.

*I. 3. Börkänçek yabu.*

Yäş kilengä aq börkänçek yabu yolası turında dastanda bolay äytelä: «Aq börkänçek kigän yort». F. Bayazítowa yazğança, Ästerxan tatarlarında XX ğasırnıñ axırına qädär «bitküräm tuy» yolası ütkärelgän, yäğni anda kilenneñ börkänçege açılğan[9]. Qazaqlar bu yolağa «bet aşar» («bit açar») dilär. Nuğaylarda tuynıñ ikençe köne bügen dä «bet aşar tuy» («bit açu tuyı») dip yörtelä. Törekmännär bu yola başqarılğan könne «duwaq gyunyu» dip atıylar. Kilenneñ börkänçegen açu — küp kenä törki xalıqlarnıñ tuy yolası eçendä urın alğan urtaq ğädät. Elek kilen kiäw yortına yözenä aq (yäisä al) börkänçek qaplap kilergä tieş bulğan. Ğälimnär fikerençä, bu yola — kilenne yawız, qara köçlärdän, küz tiüdän saqlaw çarası häm, älbättä, kilen bulıp töşkän qıznıñ saflığına da işarä itä[10]. Alay ğına da tügel: börkänçek saldıru — qıznıñ monnan soñ başqa ber näselgä küçüen dä beldergän[11]. Bu xaqta tanılğan tyurqoloğ S. Abramzon bolay dip yaza: «Qırğız qızları, berqayçan da altay qızları kebek yözlären qaplap yörmägännär. Läkin kilen bulıp töşäse yortqa, awılğa berençe märtäbä kilülärendä bitlären «börkänçek» iseme birelgän aq tuqıma belän qaplap kilgännär»[12]. Töreklärdä äle bügen dä qız kiäw öyenä başına al yäisä qızıl töstäge börkänçek qaplap töşä. Läkin qıpçaqlarda (tatarlarda, qırğızlarda, qazaqlarda), uğızlardan ayırmalı bularaq, börkänçek aq töstä bulğan.

*I. 4. Qaplı qamqa yırtu.*

---

[8] Tağı G. Kazak Türklerinde Evlenme Geleneği // Bitirme Çalışması (yayımlanmamış). Muğla Üniversitesi basımevi, 2004, s. 26.
[9] Bayazítowa F. Ğömerneñ öç tuyı (Tatar xalqınıñ ğailä yolaları). Qazan, 1992, s. 115.
[10] Cingőz S. M. Anadolu'nun Bazı Yőrelerinde Gerdek Sabahı Gelinle İlgili Adet ve Uygulamalar Üzerine Bir Atlas Denemesi // V. Villetlerarası Türk Halk Kültürü Kongresi. Gelenek Gőrenek İnançlar Seksiyon Bildiriler. – Ankara, 1997, s. 349.
[11] Sultanğäreyewä R. A. Başkirskiy swadebno-obryadowıy folklor. Ufa, 1994, s. 99.
[12] Akmataliev A. Kırgız Folkloru ve Tarühü Kaharmanlar // Atatürk Kültür Merkezi Başkanlığı Yayınları. Ankara, 2001, s. 79-81.

«İdegäy» dastanında bezgä bik ük añlaşılıp betmägän mondıy yullar da bar:
Qaplı qamqa yırtqan yort.
«Qamqa» süze «Tatar teleneñ añlatmalı süzlege»ndä «altın-kömeş belän aralaştırıp suqqan tuqıma»[13], dip birelä. Xätta tatarlarda «kiem kisäñ qamqa ki, eçe tuzmıy, töse uñmıy», digän ber äytem dä bar häm anıñ qıymmätle häm çıdam tuqıma bulğandır digän näticä yasarğa mömkin. Dastanda, alda kürsätep ütkän yullarğa, «biredä ğädät-yola turında süz bara» dip iskärmä birelä.
Nindi ğädät-yola turında süz bara soñ «İdegäy»dä? Älbättä, bu ğädät-yola tuy waqıtında ütkärelgänder, çönki süzlektä «yırtış» süzeneñ añlatmasına qarasaq, anda: «Qıçqırışıp-şayarışıp tuy büläge itep birelgän tuqımanı yırtu yolası» dielgän häm misal itep tatar xalıq mäqäle dä kiterelgän:

*Ağay-eneneñ tartışı —*
*— Tuy büläge yırtışı*[14].

Äytelgän çığanaqta bu süzneñ dialekt üzençälege buluı turında da yazılıp ütä.
Başqortlarnıñ tuy yolalarına iğtibar itsäk, alarda kilen belän kiäwne yalğız qaldırır aldınnan ütkärelä torğan «yırtış basıu» (busağadan atlap, tuqıma östenä basu) yäisä «yırtış yırtıu» (tuqıma yırtu) yolası bar. Kiäw yeget, qız yanına kergänçe, busağada ike yağınnan ike ciñgäse totıp torğan qızıl tuqımanı ayağı belän yırtıp, här ike kisägen ciñgälärenä birergä tieş. Tuqımanı yırtu — yaña statusqa küçüne, balaçaqtan baliğlıqqa kerüne beldergän. «İdegäy» dastanında da süz näq menä bu yola-ğädät turında barğandır.
Qazaq tuylarında da qaynata öyenä cibärelgän büläklär arasına «jırtış» dip atalğan tuqımalar quyıla. Tatar xalqında da elek qızlarnıñ birnäsenä kilen büläge itep öläşü öçen tuqıma kisäkläre quyılğan.

**II. Bala tuu**.

Ğailädä bala tuu — keşe tormışındağı iñ bäxetle, iñ dulqınlandırğıç mizgellärneñ berse. «İdegäy» dastanında qaharmannarnıñ ata bulu şatlığı şaqtıy qızıqlı taswirlana.
Äsärdä Tuqtamış xannıñ igezäk qızları tuğaç bäbi tuyı uzdıru küreneşe şulay sürätlänä:

*Tuqtamıştay olı xan*
*Analıqlar aldırıp,*
*San söyägen baqtırdı.*
*Xan qaznanı açtırdı,*
*Köräkläp täñkä çäçterde,*
*Xannan xannı cıydırdı,*
*Bidän bine cıydırdı,*
*Tu biälär suydırdı.*
*Utız kön uyın qıldırdı,*
*Qırıq kön tuyın qıldırdı.* (36)

İdegäy dä, ulı tuğaç, bu şatlıqlı waqıyğanı zurlap bilgeli:

[13] Tatar teleneñ añlatmalı süzlege. 3 tomda. Qazan, 1979. C. 2 , s. 37.
[14] Tatar teleneñ añlatmalı süzlege. 3 tomda. Qazan, 1977, C. 1, s. 33.

*Atalıqlar aldırıp,*
*San söyägen baqtırdı.*
*Altınnan çümäk uydırdı,*
*Kömeştän töbäk qoydırdı.*
*Qır qurayın semäk itterde;*
*Qır qurayı qatı bulır dip,*
*Altınnan semäk qıldırdı.*
*Tu biälär suydırdı,*
*Tuqtamışnıñ sansız qol —*
*Barın-yuğın cıydırdı,*
*Yalğızıma alqış tisen dip,*
*Ölkän ber tuy qıldırdı.* (37)

Biredä törki xalıqlarda bala tuğannan soñ ütkärä torğan yolanıñ zarurí räweştä cirenä citkerep ütkärelgän buluı çağıldırılğan.
Xäzer bäbi tuyı öçen motlaq bulğan qayber momentlarğa tuqtalıyq.

*II. 1. Analıqlar (atalıqlar) aldıru, san söyägen baqtıru.*

Berençese añlaşıla kebek — qız bala tuğaç, tärbiäçe itep ölkän xatınnar çaqırıla; ir bala tuğaç, — ölkän yäştäge irlär alına. Ä biredä telgä alınğan «san söyägen (başqa ber oçraqta — xan söyägen) baqtıru» turında älegä qädär açıqlanmağan.
Borınğı törkilär şamanlıq belän bäyle ber kitap barlığına ışanğannar. Ämma anı, imeş, käcä aşıy häm andağı böten mäğlümat anıñ san söyägenä küçä. Şuña kürä dä, käcäneñ san söyägenä qarap, keşeneñ ütkänen häm kiläçägen belep bula, dip uylağannar. Bu räweşle küräzälek qılu ısulı, qayber üzgäreşlär kiçersä dä, törki xalıqlar arasında ğasırlar buyı yäşäp kilgän. Ul, xätta, borınğı grek kötüçelärenä dä bilgele bulğan. Bu küräzälek itüneñ tärtibe tübändägeçä: ğädättä sarıqnıñ, siräk oçraqlarda käcäneñ yäisä alar urınına başqa ber xaywannıñ (mäsälän, çuqçalar kiekneñ, qöreyälılar isä tyülenneñ) san söyägen alğannar. İñ möhime — xaywan yaña suyılğan bulırğa tieş. Söyäk qırıyındağı itlärne bik zur tırışlıq belän yunıp alğannar häm anı, cawap alırğa telägän sorawnı uylap, utta quırğannar. Ğälimnär bu tör küräzäçelekneñ xaywan täneneñ üzenä cıyğan köçe belän bäyle buluı turında söylilär[15]. Utta quırılğan san söyäge çıtırdap quysa, suğışqa yurağannar.
San söyäge belän fal açu turında Mäxmüt Qaşğäri süzlegendä (XI ğasır) dä äytelä, Rubruq yazmasında (XIII ğasır) da telgä alına. Farsı ğälime häm däwlät eşleklese Räşidetdin dä üzeneñ yazmasında: «Arğunnıñ awıruı turında ber fiker alu öçen, şamannar, üzläreneñ qağıydälärenä kürä, ber san söyägen bik centekläp tikşerdelär», dip yaza.
Monğollar san söyäge belän küräzälek itüne «dallacı» dip, törki xalıqlar isä «yağrıncı» dip atağannar. Soñğıraq däwerdä bu räweştä fal açu Aqsaq Timer Urdasında (İbne Ğäräbşah yazğança), säfäwilär çorında İranda häm Urta Aziägä xas tormış-könküreşne üzlärendä saqlap qalğan Misır mämlüklärendä dä oçrıy. 1771 yılda qazaqlar arasında säyäxät itkän ber rus polqovniğı da alar arasında san söyäge belän küräzälek itü turında yazıp ütä. Ul qırğız xalqında da küzätelä. Mäsälän, «Manas» dastanında Manasnıñ duslarınıñ berse tölgöçü (fal açuçı) Qara Tölek, ikençese isä yağrınçı (qalaq söyäge belän fal açuçı) Qara Bädiş telgä alına. A. İnannıñ küzätüençä, Törkiäneñ Anatolia öleşendä qalaq söyäge belän fal açu XX ğasırnıñ 60 yıllarına qädär däwam itkän.
«İdegäy» dastanında da Tuqtamış xan belän İdegäy, äti keşe bularaq, balalarınıñ kiläçäge belän qızıqsınıp, san söyägen baqtıralar. Kiläçäktän

[15] Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların… s. 74-75.

xäbär alu teläge — keşelärgä tarixnıñ här däwerendä xas bulğan küreneş. Qalaq söyäge belän bağuçılıq itü isä tatarlarda elek tä kiñ qullanılğan. Mäsälän, xalıq ışanuları arasında, «utta quırılğan qalaq söyägeneñ öske yağı buyğa yarılsa, eşeñ (yulıñ, niäteñ, ğıyşqıñ) xäyerle bulır, ägär dä inde söyäkneñ öske yağı iñgä yarılsa — xäyersez bulır», dip farazlanğan. Qalaq söyäge östenä borçaq sibep açılğan fal töre dä bulğan, läkin anıñ mäğnäse onıtılğan[16].

Dastanda «san söyägen baqtıru» dielä. San söyäge — gäwdä söyäge digän mäğnädä kilä. Bu falnı «qalaq söyäge belän yuraw» dip tä äytä torğan bulğannar. «Qalaq» süzeneñ tatar telendä ber añlatması «köräk şäkelendä» dip birelä. Dimäk, süz şul uq köräk söyäge turında bara. Bu tör falnı açuçılarğa yawırınçı digännär (yawırın — arqa, qalaq söyäge, köräk söyäge).

«İdegäy» dastanında mäcüsi ğälämätlärennän bağu ğädäte yış oçrıy. Mäsälän, Tuqtamış xan İdegäyneñ kem buluın açıqlaw öçen küräzäçe Subra cırawnı çaqırta. Alıp Qara Tien dä üzeneñ kem qulınnan üläçägen bağuçıdan belüe turında bolay söyli:

*Gürem qayda — belmädem,*
*Ülemem kemnän — belmädem;*
*Baqçıdan bağım baqtırdım,*
*Falçıdan falım açtırdım,*
*Sınçıdan sınım sınattım,*
*Anda beldem bu eşne:*
*Mine ütergän ir bulsañ —*
*Ul sin ikän, İdegäy! (103-104)*

*II. 2. Täñkä çäçü.*

Kilgän qunaqlar östenä altın-kömeş täñkälär sibü dä borınğıdan kilgän yolalarnıñ berse. Mäsälän, İbne Fazlan säyäxätnamäsendä Bolğar padíşahınıñ alarnı qarşı alırğa çığuı turında «Ciñendä täñkälär bar ide, alarnı bezneñ öslärebezgä çäçte», dip yaza[17].

Täñkä, qayber ğälimnär fikerençä, bik borınğı çorlarda Täñregä tabınunıñ ber simwolı bulıp torğan. Bigräk tä kömeş täñkägä, çönki kömeş tös kük tösen xäterlätä häm borınğı ğasırlardan uq Kük Täñre belän aralaşunı belderep torğan. Täñkä çäçü ğädäte, ğömümän, küp kenä bäyrämnärgä dä xas bulğan[18]. Dastanda, mäsälän, Şah Timer dä, qızın qotqarıp alıp qaytqan İdegäy yanına çıqqaç şulay eşli:

*İläkläp altın çäçterde,*
*Köräkläp kömeş çäçterde. (111)*

Täñkä çäçü, berençedän, sälamläw, xuş kürü, ilahi zatlardan märxämät teläw simwolı bulsa (ğädättä, söyeneçtän eşlängän), ikençedän, mul tormışnı da kürsätep häm teläp torğandır dip, farazlarğa mömkin. Ä bälki, monda timerneñ mağik köçkä iä bulıp, qara köçlärne yuq itü öçen qullanıluın da iskä alırğa kiräkter. Mäsälän, R. A. Soltangäräyewä yazğança, näq menä bu teläk belän

---

[16] Tatar mifları. Qazan, 1996, s. 267, 269.
[17] Fäxretdinov R. Bolğar wä Qazan törekläre. Qazan, 1993, s. 67
[18] Sultanğäreyewä R. A. A.g.e., s. 10, 23

borıñğı keşelär dä, kilgän qunaqnıñ ayaq kiemeneñ ükçäse astına täñkä quya torğan bulğannar (naçarlıqnıñ keşe ükçäsendä yäşäwenä ışanğannar)[19].

*II. 3. Tu biälär suydırıp tuy yasaw.*

Dastanda bala tuğaç, tu biälär suyıla. Kük Täñregä ışanu sistemasına xas bulğan kebek, qorban çalu ğädäte küp kenä dinnärdä dä oçrıy. Qor'ändä Allahe Täğäläneñ: «Bez här ömmät öçen qorban çalunı şariğät qanunı itep qabul qıldıq», digän süzläre bar (Xac süräse, 34 ayät). Mäsälän, skiflarda at häm sarıq qorban itelgän. Kük törkilär dä bişençe ayda ütkärelgän milli häm dini bäyrämnärdä Täñregä küp itep at häm sarıq qorban itkännär[20]. Monğollarda häm törkilärdä borıñğı ğasırlarda, äle íslam dine kergänçe ük, qorban itep at çalu kiñ taralğan bula.
Bolğarlarda da yılğa ber tapqır Qorban köne («qan kön») ütkärelgän. Ul xäzerge çärşämbe könenä turı kilgän. Qorban itelgän xaywan, ğädättä, aq yäisä sarı töstä häm iñ ähämiätlese — äle eştä qullanılmağan, qolınlamağan buluı şart itelgän[21]. Monğollarnıñ iñ yaratqan häm xörmät itkän töslereneñ dä aq tös buluın äytergä kiräk. Ğömümän, aq tös baytaq dinnärdä häm xalıqlarda saflıq, päqlek simwolı bulıp sanalğan. A. İnan da aq tösle xaywannarnıñ täñrelär tarafınnan yaratılğan häm ruxlarnıñ da xuşına kilä torğan buluı turında yaza[22]. Qırğız xalqınıñ «Manas» dastanında da Manas tuğaç, atası aq büz biä suydıra.
Tu biä digändäge «tu» süze isä «qolınlamağan» mäğnäsendä kilä. Qolınlamağan biä yäş bulğanğa kürä anıñ ite dä yomşaq häm tämle bula. İdegäy Aqbeläkne qotqarıp alıp qaytqannan soñ da, Şah Timer tu biälär suydırıp, tuy yasıy. Kilgän qunaqqa aş birü yolasınıñ da bik borıñğı çorlarğa barıp totaşuı mäğlüm. Bolğar padíşahı, qunaqlarnı üz köbbäsenä çaqırıp, alarğa aş äzerlätüe turında İbne Fazlan da yazıp qaldırğan[23]. Zurdan qubıp, mäcles-aşlar ütkärü ğädäte Bolğar çorında uq xas bula.
Elek-elektän törki xalıqlarda, bala tuğaç, aq biälär suyılıp, aş ütkärü ğädäte — şatlıq-söyeneç, bäxet kitersen digän teläk belän başqarılğan[24]. A. İnannıñ fikerençä, törki xalıqlarda qorban çalu häm aqça, yäisä berär aşıy torğan rizıq sibü ğädäte — ul Täñre rizalığı öçen, annan yärdäm sorap, teläklärneñ qabul itelüe öçen dä başqarıla torğan bulğan[25].
Läkin dastanda Tuqtamış xan belän anıñ xezmätendä bulğan İdegäy ütkärgän bäbi tuylarında, däräcälärgä bäyle räweştä, qayber ayırmalıqlar çağılış tapqan. İgezäk qızları tuğaç Tuqtamış xan bäyrämne şulay ütkärä:

*Xannan xannı cıydırdı,*
*Utız kön uyın qıldırdı,*
*Qırıq kön tuyın qıldırdı.(36)*

Mondıy tuynı dastanda barı tik tağın ber keşe — şulay uq xökemdar bulğan Şah

---

[19] A.g.e., s. 71
[20] Turan O. Selçuklu Tarihi ve Türk İslam Medeniyeti. İstanbul, 1980. 3. baskı, s. 401.
[21] Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların… s. 194
[22] İnan A. Tarihte ve Bugün Şamanizm… s. 101.
[23] Fäxretdinov R. A.g.e., s. 67-68.
[24] Yıldız N. Manas Destanı ve Kırgız Kültürü ile İlgili Tespit ve Tahliller. Ankara, 1995, s. 252.
[25] İnan A. Eski Türk Dini Tarihi. İstanbul, 1976, s. 46-54.

Timer genä uzdıra ala. Qızı Aqbeläk Qara Tien Alıptan qotqarılğaç ul şundıy mäcles oyıştıra:

*Şah Timerneñ sansız qol —*
*Barın-yuğın cıydırdı,*
*Tu biälär suydırdı,*
*Utız kön uyın qıldırdı,*
*Qırıq kön tuyın qıldırdı. (112)*

İdegäy isä, ulı Noradın tuğaç ütkärgän bäbi tuyı turında, bolay di:

*Sin tuğanda, Noradın,*
*Tu biälär suydırdım,*
*Altı könläp aş birep,*
*Ğälimnärne tuydırdım,*
*Cide könläp aş birep,*
*Yätimnärne tuydırdım… (194)*

Kürengänçä, İdegäy üz xälenä kürä tuy uzdıra häm, iñ ähämiätlese, ul anda ğälimnärne dä cıyarğa, yätimnärne dä söyenderergä onıtmıy. Biredä inde İdegäyneñ keşeleklelege belän bäyle kürkäm sıyfatları açıqlana. Näq moña oxşaş moment «Manas» dastanında da bar — Manasnıñ atası, ulı tuğaç, tuymağannarnı tuydıra, açlarğa aş birä:

*Cäntäkkä sigez biä çalğan,*
*Tuymağannı tuydırğan,*
*Tärbiäle xaywannarnı suyğan,*
*Aç bulğannarnı tuydırğan.*

Xalıqqa xezmät itü, anı olılaw, sıylaw — törki dastannarda yumartlıq çağılışı bulıp tora. Qaharmannarnıñ mondıy yumartlığın «Uğız» dastanında häm «Dädäm Qorqıt kitabı»nda da küreregä mömkin.

*II. 4. İsem quşu.*

Törki xalıqlar arasında isem quşu — borınğıdan kilä torğan iñ kürkäm yolalarnıñ berse. Ul «İdegäy» dastanında cirenä citkerep başqarıla. Mäsälän, Tuqtamış xannıñ üz qızlarına isemnär quşu şulay äytelä:

*Olı qızı ayğa tiñ —*
*Atın quyıp Xanäkä,*
*Köçe qızı köngä tiñ —*
*Atın quyıp Könäkä,*
*Küñelen anda tındırdı. (36)*

İdegäy dä ulına mäğnäle isem quydıra:

*Xan qarşında tudı dip,*
*Atın Noradın quydırdı. (37)*

Borıñğı yola buyınça, balağa isemne atası quşa. Bez monı altay dastanı «Mağaday-Qara»da da kürabez: Altın-Tarğa, balasına isem quşu öçen, ireneñ awdan qaytuın kötä[26]. Qayber dastannarda balağa isemne Xızır quya. «İdegäy» dastanında isä yaña tuğan qızlarına isemnärne Tuqtamış xan, ulına — İdegäy quşa.
İsemne balağa izge teläklär teläp, zur ömetlär bağlap quşqannar. Bu — ayırım ber ähämiätkä iä bulğan yola. Balağa isem quşu yolası da tamırları belän bik borıñğı çorlarğa barıp totaşa: keşelär äle tel yaralğan däwerdä ük äyberneñ iseme cisemenä turı kilergä tieş dip uylap, dönyada här närsägä — cansız äyberlärgä, tereklek iälärenä, keşelärgä isemne, alarnıñ berär üzençäleklärennän çığıp quşqannar[27]. Borıñğı hind çığanağında «isem — keşelärneñ tormışlarındağı iñ ähämiätle närsäder. İsem keşeneñ yazmışın bilgeli. İseme belän keşe şöhrät-dan qazana. Şuña kürä, isem quşu yolası — iñ zur maqtawğa layıq yoladır», dielä[28].
Ğädättä, yaña tuğan balanı ayğa, köngä (yäğni qoyaşqa), nurğa, yoldızğa tiñlägännär. «İdegäy» dastanında telgä alınğan isemnärneñ, bötenese diärlek, törki çığışlı — Qotlıqıya, Cantimer, Qobağıl, İdegäy, Tuqtamış, Urman, Subra, Qara Tien, Timer, Noradın, Aytulı, Aqbeläk, Yänikä, Xanäkä, Könäkä, Canbay. Xätta ğäräp telennän kergän Qadıyr isemenä dä törki qomponent «birde» quşılğan.

İSKÄRMÄLÄR:

1. İdegäy. Tatar xalıq dastanı. – Qazan, 1988. – 254 b. (Misallar älege çığanaqtan alındı häm bit sannarı şunnan kürsätelä. — Ç. Z.-Ç.).
2. Suleymanowa-Waleyewä G. Tipologia vzaímodeystwiä xudojestwennoy kulturı tatar v sisteme «Wostoq — Zapad» // Tatarica. Zwezdnıy ças tatarsqoy istorii. – Qäzän, 1997. – S. 113.
3. Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların Eski Dini / Çeviren A. Kazancıgil. – İstanbul. – 2 baskı. – 1998. – S. 14.
4. İnan A. Tarihte ve Bugün Şamanizm. – Ankara, 1995. – S. 11-12.
5. Ergun M. Alıp Manas. – Ankara, 1998. – S. 102.
6. İnan A. Makeleler ve İncelemeler. – Ankara, 1987. – Cilt 1. – S. 140-141.

7. Őgel B. Türk Mifolojisi. – Ankara, 1993. – Cilt 1. – S. 105.
8. Tağı G. Kazak Türklerinde Evlenme Geleneği // Bitirme Çalışması (yayımlanmamış). – Muğla Üniversitesi basımevi, 2004. – S. 26.
9. Bayazítowa F. Ğömerneñ öç tuyı (Tatar xalqınıñ ğailä yolaları). – Qazan, 1992. – B. 115.
10. Cingőz S. M. Anadolu'nun Bazı Yőrelerinde Gerdek Sabahı Gelinle İlgili Adet ve Uygulamalar Üzerine Bir Atlas Denemesi // V. Villetlerarası Türk Halk Kültürü Kongresi. Gelenek Gőrenek İnançlar Seksiyon Bildiriler. – Ankara, 1997. – S. 349.
11. Sultanğäreyewä R. A. Başkirskiy swadebno-obryadowıy folklor. – Ufa, 1994. – S. 99.
12. Akmataliev A. Kırgız Folkloru ve Tarühü Kaharmanlar // Atatürk Kültür Merkezi Başkanlığı Yayınları. – Ankara, 2001. – S. 79-81.
13. Tatar teleneñ añlatmalı süzlege. 3 tomda. – Qazan, 1979. – 2 t. – B. 37.

---

[26] Maaday-Qara. Altayskiy geroiçeskiy epos. Ğorno-Altaysk, 1995, s. 25.
[27] Zäkiev M. İseme cisemenä turı kilsen // G. F. Sattarov. Tatar isemnäre süzlege. Qazan, 1981, s. 3.
[28] Randey P. B. Drevneindiyskie domaşnie obryadı. M., 1982, s. 87.

14. Tatar teleneñ añlatmalı... – Qazan, 1977. – 1 t. – B. 33.
15. Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların… – S. 74-75.
16. Ibid. – S. 75-76.
17. Tatar mifları. – Qazan, 1996. – B. 267, 269.
18. Fäxretdinov R. Bolğar wä Qazan törekläre. – Qazan, 1993. – B. 67.
19. Sultanğäreyewä R. A. Uqaz. soç. – S. 10, 23.
20. Tam je. – S. 71.
21. Turan O. Selçuklu Tarihi ve Türk İslam Medeniyeti. – İstanbul, 1980. – 3 baskı. – S. 401.
22. Jean-Paul R. Türklerin ve Moğolların… – S. 194.
23. İnan A. Tarihte ve Bugün Şamanizm… – S. 101.
24. Fäxretdinov R. Kürs. xez. – B. 67-68.
25. Yıldız N. Manas Destanı ve Kırgız Kültürü ile İlgili Tespit ve Tahliller. – Ankara, 1995. – S. 252.
26. İnan A. Eski Türk Dini Tarihi. – İstanbul, 1976. – S. 46-54.
27. Maaday-Qara. Altayskiy geroiçeskiy epos. – Ğorno-Altaysk, 1995. – S. 25.

28. Zäkiev M. İseme cisemenä turı kilsen // G. F. Sattarov. Tatar isemnäre süzlege. – Qazan, 1981. – B. 3.
29. Randey P. B. Drevneindiyskie domaşnie obryadı. – M., 1982. – S. 87.